***МИССИОНЕРСКИЙ ЛИСТОК***
***КРЯШЕНСКАЯ ДУХОВНАЯ МИССИЯ (http://www.missiakryashen.ru)***

# ЖАЗЫК ӐЙТЕЎ ЖЯШЕРЕГЕ ТУРЫНДА (О ТАИНСТВЕ ИСПОВЕДИ)

Жазык ӓйтеў былай була: кеше Алла алдында жазыклы булганын тойоб, аны кылганына ўкеня, жазыкларын исеня китереб, священник алдында Алланын Ўзеня ӓйтя. Священник Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя анын жазыкларын чишя. Чын кюнелдян жазыкларга ўкенеб тяўбя иткяне ӧчӧн, священник арткылы Ходай Иисус Христос Ўзе кешегя жазыкларын кичереб бетеря. Жазык ӓйтеўне Ходай Иисус Христос Ўзе куйган. Ул апостолларга ӓйткян: ***«Святый Тынны алыгыз: сез кемгя жазыкларын кичерсягез, шунар кичерелер, кемгя кичермей калдырсагыз, шунар кичермей калдырылыр, дигян»*** (Ин.20, 22-23). Христоска ышанган кеше геня, чумылган кеше геня жазык ӓйтя алала.

## ЖАЗЫК ӐЙТЕБ, ТЯЎБЯ ИТЕЎЧЕ КЕШЕНЕН УЙЛАНА ТОРГАН УЙЛАРЫ

Эй кадерле ӓтей, синен алда Алла Ходайыма бӧгӧнгя, бу сагяткя кадяр эшем белян, сюзем белян, уйым белян санаб бетергесез кылган жазыкларымны ӓйтямен. Аллага тау итмей тороуым белян, иманнар укыб, теляк итмей тороуым белян жазыкланам. Кюремчеляргя жӧрӧўем белян, буш сюзляр сӧйляўем белян, кеше тикшереўем, кеше сӧйляўем белян, олосомакланыу, изгелек кылмауым белян, кӧнчӧлӧк итеўем, ачыулы булыуым белян, усаллыкны истя тотоуым, усаллыкка усаллык эшляўем белян, зарланыуым, карышы ӓйтеўем, чянчеб ӓйтеўем белян, жалганнауым белян, ўземне геня сӧйӧўем белян, дан сӧйӧўем белян, кюнелемне биреб ӓйбер, акча сӧйӧўем белян, уйнашлык итеўем белян, шакшы уйнашлык итеў уйларын башыма кертеўем белян, хыялымда азгыннык итеб алардан рахятлек алыуым белян, азгыннықны жаратыуым белян, аборт ясатыуым белян, урлау белян жазыкландым. Бютяннярне кимсетеўем белян, тянгя геня жарарга тырышыуым белян, артык ашау белян, оят сюзляр ӓйтеў белян, мыскыллаб кӧлӧўем белян, мал жыйыуым белян, ураза тотмауым белян, арыу эшляр кылмыйчы тик тороуым белян жазыкландым. Саранныгым, талашыуым белян, сюгенеўем, исереб жӧрӧўем белян, бушка Алланын исемен чакырыу белян, кеше ӓйбереня кызыгыуым белян, кеше кайгысына сӧйӧнеўем белян, усаллыкка котортыуым белян, каргау сюзлярен ӓйтеўем белян, кешегя бяля, чир, ўлем теляўем белян, Евангелиене, Псалтирне тагы бютян арыу книгялярен укырга жалкауланыуым белян, келяўгя жӧрмягянем белян, хяйер бирмягянем белян.

Коткарыучы Христос алдында ўкенеб тяўбя итямен, чын кюнелемнян тюбян жыгылыуыма сызланамын, инде алга таба, булдыра алган кадяр, Алланын изгелеге, булышлыгы белян тяннен дя, тыннын да ӓр-бер шакшылыгыннан ўземне саклаб тотармын диб ирек итямен. Эй кадерле ӓтей, мине кичер, чиш, мин жазыклы мяндя ӧчӧн иняля кюр.

***Ӧй-хужалыгында кулланмаска!***